Хәрәкәтле уеннар


**Күз бәйләш**

Уйнаучылар түгәрәкләнеп тезеләләр, түгәрәкнең уртасында ике бала басып тора. Аларның берсенең күзен бәйлиләр, ә икенчесенә кечкенә кыңгырау бирәләр. Беренче бала кыңгыраутавышы буенча иптәшен тотарга тырыша, әђ икенчесе ничек булса да тоттырмаска тырыша. Ул тотылганнан соң, түгәрәк уртасына башка балалар керәләр.

**Узышчылар**

Балалар парлашып, бер-бер артлы тезелеп басалар. Уйна- учылардан 20–25 м ераклыкта сызык үткәрелә яисә бу урын флаглар белән билгеләнә. Уйнаучылар барысы бергә: «Бер, ике, өч!» – дип кычкыралар. Шуннан соң беренче булып басып торган ике бала флагларга кадәр йөгереп барып, кире йөгереп әйләнеп кайталар. Икесе дә бер-берсен узарга тырыша. Кире әйләнеп кайткан балалар артка басалар, аннан соң икенче пар йөгерә.

***Бергәләп өйрәник***



***Исәнме, балалар бакчасы!***

***Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек***

***(6-7 яшь)***

**Җырлы-биюле уен «Наза».**

Балалар, парлашып, бер-бер артлы тезелеп басалар. Бер бала парсыз, ул уенчылар каршысына чыгып баса.

Наза дигән кыз баланың

Бөрлегәне түгелгән.

«Наза» дигән уенны без

Уйныйбыз чын күңелдән.

Кушымта: Наза, Наза,

Наза – матур кыз бала.

Наза тырыш, уңган бала,

Зирәк, акыллы бала.

***Тот яхшы тәрбиядә***

Яңгырларга бирешми,

Ләкин онытма шуны:

Пычрак йөртү килешми,

Бик ярата ул суны,

Бернинди дым сеңдерми,

Кояшны һәм сабынны,

Тузганлыгын сиздерми.

Чыныкканда, салкынны.

Бөгәрләнми бөртек тә,

Аннан башка беркем дә

Ә һава яхшы үтә.

Яши алмый бер көн дә.

Йөз ел яшә, барыбер

Тот яхшы тәрбиядә,

Гомер буена җитә.

Нәрсә соң ул, әйт, әйдә?! (Тән тиресе) ***Заһирә Гомәрова***

**Мәкальләр**

*Бит күрке — күз, тел күрке — сүз.
* Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел.
* Сүз бирсәң — үтә.
* Ничек эндәшсәң, шулай ишетерсең.
* Аз сөйлә, күп бел

Яттан өйрәнү өчен

***Мәктәп***

Җәй үтеп, көз җиткәч үк,

Инде башланды дәресләр,

Мәктәп күзен ачты тагын;

Инде мәктәп җанлана;

Ялтырап китте урамнар,

Нинди шат, нинди бәхетле

Басты нур төрле ягын...

Монда кергән һәр бала!

Нәҗип Думави